РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
СТАРОКАРАМАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423982, Р.Т. Муслюмовский район, с.Старые Карамалы, ул.Кооперативная 115а,*
Skarm.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-54-25*
ИНН 1629003858, КПП 162901001, ОГРН 1061687001144, ОКАТО 92242870001.

*Иске Карамалы авылы* *«06» 03 2021 г.*

**КАРАР №6**

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Иске Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иске Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 24 нче февраль 4 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибенә түбәндәгеләрне өстәп, үзгәреш кертергә**:**

**1.1. 10 пунктның 2 абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән дәвам итәргә:** «һәм мәҗбүри рәвештә салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булмау турында Россия Федераль салым хезмәтеннән белешмә.».

**1.2. 10 пунктны 3 абзац өстәргә:** «мөрәҗәгать итүче 10 пунктның 2 абзацында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, җирле үзидарә органы ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләрне мөстәкыйль рәвештә соратып ала».

**1.3. 20 пунктны түбәндәге 4 пунктча белән тулыландырырга:** «4) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Л.М.Хәлиуллина**